ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» 11 2020г.** **№875**

«2021 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгати-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 14.12.2009 ел, №854 карары һәм "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга расларга:

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә теркәлгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе С.П Самонина

А. В. Сучкова
2-80-12

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____» ________ 20ел №___карары белән
расланды

# «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашкан урыны | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | шәһәр җире | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | авыл җире | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җире | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җире | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җире | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җире | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җире | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җире | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җире | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җире | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җире | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җире | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җире | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җире | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |